Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Кодаш торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**22 ноябрь 2023ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның "22" ноябрендә 13 сәгать 00 минутта уткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2024 елда үзара салым акчаларын кертү өчен «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, студентлардан, көндезге формада белем алучы гражданнардан, шулай ук Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юллау белән килешәсезме:

1. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларына куелган һәйкәлне реконструкцияләү; трактор өчен асылма җиһазлар (чапкыч) сатып алу.

2. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү,койма тоту.

3.Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(Кодаш авылында сууткәргеч ремонтлау, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары һәм су күтәрү манарасы өчен башка материаллар сатып алу).

4.Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомашинасын карап тоту, ремонтлау, запас частьләр сатып алу; янгын сүндерү машинасын йөртүчегә шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урамнарны кардан чистарту; үлән чабышлары; дизель ягулыгы сатып алу; тракторчы килешүе буенча хезмәт өчен түләү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 152 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 79 кеше, бу 52 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 79 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Кодаш торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. Көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан (контракт буенча хәрби хезмәткәрләр, мобилизацияләнгән, ихтыярый затлар) һәм аларның гаилә әгъзаларыннан (ата-аналар, ир белән хатын, балигъ булган балалар), ирегеннән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, 2024 елда Кодаш авыл җирлеге территориясенең Кодаш авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү (Бөек Ватан сугышында катнашкан якташларына куелган һәйкәлне реконструкцияләү; трактор өчен асылма җиһазлар (чапкыч) сатып алу.

2. Традицион күмү урыннарын төзекләндерү,койма тоту.

3.Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау(Кодаш авылында сууткәргеч ремонтлау, хезмәт күрсәтү, тирәнлек насослары һәм су күтәрү манарасы өчен башка материаллар сатып алу).

4.Янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгын сүндерү автомашинасын карап тоту, ремонтлау, запас частьләр сатып алу; янгын сүндерү машинасын йөртүчегә шартнамә буенча эшләр өчен түләү).

5. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (урамнарны кардан чистарту; үлән чабышлары; дизель ягулыгы сатып алу; тракторчы килешүе буенча хезмәт өчен түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек башлыгы Ф.М.ШАКИРОВ

Совет Кудашевского сельского поселения Кодаш авыл җирлеге Советы ИНН 1601002501